| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » 02 2021 № 36

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 ел, 13 октябрь, 646 номерлы карарына (2021 елның 12 гыйнварындагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 елның 26 ноябрендәге 651 номерлы карары нигезендә, һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше нәтиҗәләре буенча һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча 2011 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 елның 13 октябрендәге 646 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2.6 п. «Норматив хокукый актларга туры китереп, муниципаль хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларда әмердә булган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар белән әмер итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешма.»

түбәндәге эчтәлектә абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләр - Россия ФСХ.»;

1.2. 2.8 п. «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеген» түбәндәге эчтәлектә 5) абзац өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

1.3. 3.4.1п. «Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон багланышлар системасы ярдәмендә түбәндәгеләрне бирү турында сорауларны җибәрә:» түбәндәге эчтәлектә 3) абзац өстәргә:

«3) салымнар, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.».

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 13.10.2020 ел, № 646 карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2.6 п. «Норматив хокукый актларга туры китереп, муниципаль хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларда әмердә булган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар белән әмер итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешма.»

түбәндәге эчтәлектә 5) абзац өстәргә:

«5) «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләр - Россия ФСХ.»;

2.2. 2.8 п. «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеген» түбәндәге эчтәлектә 5) абзац өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

2.3. 3.4.1 п. «Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон багланышлар системасы ярдәмендә түбәндәгеләрне бирү турында сорауларны җибәрә:» түбәндәге эчтәлектә 5) абзац өстәргә:

«5) салымнар, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.».

3.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 13.10.2020 ел, № 646 карары белән расланган агач һәм куак кисүгә, ябалдашлауга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. 2.6 п. «Норматив хокукый актларга туры китереп, муниципаль хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларда әмердә булган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар белән әмер итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешма.»

түбәндәге эчтәлектә 2) абзац өстәргә:

«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләр - Россия ФСХ.»;

3.2. 2.8 п. «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеген» түбәндәге эчтәлектә 5) абзац өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

3.3. 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек белгече ведомствоара электрон багланышлар системасы ярдәмендә Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан (үз эченә алган күчемсез мөлкәт объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар) өземтә бирү турында сорауны һәм законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында сорауны җибәрә».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan. ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев